# Илле ел «Ләйсән» берләшмәсендә

**Армия хезмәтеннән соң, 1976 елның башларында, Чаллыга килгәч Двигательләр заводында оператор булып эшли башладым**.

КАМАЗ заводлары инде төзелеп беткән диярлек. Шәһәрнең үзендә дә ай саен яңа йортлар калка, Чаллының яшь үсеш чорлары. Эштән соң ял итәргә, кино карарга яңа гына ачылган «Батыр» кинотеатры бар. Ләкин романтик, шигъри җанлы күңелгә бу гына аз, нидер җитеп бетми кебек иде. Шулай берчакны яз айларында эштән кайтып килгәндә заводның 28/10 тулай торагы янында таза бәдәнле, кояш кебек көләч йөзле бер кеше белән сөйләшеп торырга туры килде. Шигырьләр язуым турында әйткәч, ул миңа «Энергетик» мәдәният йортында «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе эшләвен әйтте. Бераздан «Ләйсән»леләрнең очрашу вакытын белеп, бу оешмага килеп йөри башладым.

Ул чорда башлап язучылар белән Язучылар берлеге әгъзалары да бергә җыелалар иде. Зур язучыларның, шагыйрьләрнең әсәрләрен укып тикшергәндә берләшмәгә әле яңа аяк баскан, каләм тибрәтә генә башлаган кешеләр дә катнаша, аларның фикерләре дә тыңлана иде. Шагыйрьләр Кадыйр Сибгатуллин. Хәниф Хөснуллин. Рахман Хисмәтуллин, Ямаш Игәнәй, Эдуард Касыймов, Рахман Шәфигуллин, Факил Сафин, берләшмәгә юлны күрсәткән кояш йөзле Миркадәм Матшин, Равил Вәлиев белән танышып, аралашып яшәү җан рәхәте, күңел тынычлыгы бирә иде миңа. Үзем шигырь дип уйлап такмак рәвешендә генә язган чорымда шигырьнең нәрсә икәненә төшендерүче Кадыйр абый булды. Үзеңнең җаныңда йөргән фикерләрне төгәл үк әйтеп бирә алмаганда ул булышты, аның сихри көче канат бирде. Соңрак, 80нче еллар башында, «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе җыелышлары яңа гына төзелеп беткән 3/01 йортының беренче катындагы зур гына бүлмәсендә үткәрелә башлады. Ул елларда «Ләйсән»леләр арасында 1979 елда Казан китап нәшриятында басылган «Яшьлегем Чаллы» китабында урын алган яшь каләм ияләре Рәйсә Фәхразыева, Тәнзилә Сәгыйтова, Сәлимә Шәрипова, Әлфия Ситдыйкова, Фирая Хәлиуллина, Венера Хәбибрахманова, Нәсих Таҗиев, Фирдәвес Бәширова, Рәшит Хәйретдинов бар иде.

«Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе елдан-ел тулыланды. Берләшмәгә үзенең матур-матур җырлары белән Мирһади Разов килеп керде. Соңрак Салават Гатауллин йөри башлады. Рәкит Әбделмәнов, Амур Фәләх үзләренең шигырьләре, хикәяләре белән чаллыларның күңелләренә үтеп керде. «Ләйсән»леләр Чаллы халкы алдында да, татар халкы каршында да йөзләрен кызартмадылар. «Ләйсән» берләшмәсенә соңрак кергән Зифа Кадырова бүген зур танылу алды.

Күп еллар үтте, элегрәк Равил Лотфуллин, Рафис Сәлимҗанов, Мәхмүт Газизов. Фирдәвес Бәширова, Айдар Хәлим, Факил Сафин, Рәшит Бәшәр җитәкләгән берләшмәне 2007 елдан ягымлы, тыйнак, акыллы, зыялы, бөек тел галимебез Гомәр Саттаровны биргән Яшел Үзән районы Мулла Иле авылы кызы Роза Хәмидуллина җитәкли. Роза әдәби берләшмә очрашуларын мәгънәле, кирәкле итеп алып бара. Яңа гына каләм чарларга керешкән кешеләрне дә шигырь, проза серләренә төшендерә белүче, төпле җитәкче. Берләшмәгә килеп аралашып, сөйләшеп утыру да үзе бер бәйрәм, үзе бер җан рәхәте.

Равил Мостафин,
17 китап авторы,
1976 елдан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы